Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Рус Акташы авыл Советы

# КАРАР

14 декабрь 2023ел № 80

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 26 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 2 ноябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы нигезендә

Рус Акташы авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1.Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмә хакында» 2021 елның 28 октябрендәге 26 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Рус Акташы авыл Советының 2023 елның 20 февралендәге 59 номерлы, 2023 елның 1августындагы 72 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәткәрләргә класслы чиннар бирү һәм муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларына күчергәндә һәм муниципаль хезмәттән азат ителгәндә аларны саклап калу тәртибе» 4 бүлегендә карарга кушымталар:

- 4.6 пунктындагы 4.6.1 пунктчасында икенче җөмләне төшереп калдырырга;
- 4.10 пунктын үз көчен югалткан дип танырга;
- 4.13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль хезмәткәргә класслы чин бирү турындагы карар, 4 бүлекнең 4.7 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затына барлык кирәкле документлар белән класслы чин бирү турында тапшыру кертелгән көннән алып бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Рус Акташы авылы, Төзүчеләр урамы, 14 нче йорт, Комсомол урамы, 12б йорты территориясендә; Акташ станциясе контора торак пункты территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәренең Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Рус Акташы
авыл җирлеге башлыгы С. А. Белоногов